ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының $10^4$ һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $10^4$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$10^4$ статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында депутатлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәү (тиешенчә үтәмәү) хакындагы гомумиләштерелгән мәгълүматны урнаштыру тәртибе**

1. Комиссия ел саен 20 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру өчен депутатлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәү (тиешенчә үтәмәү) хакында гомумиләштерелгән мәгълүмат җибәрә (мондый мәгълүматта тиешле затны идентификацияләү мөмкинлеге бирә торган персональ

белешмәләр һәм тиешле зат ия булган мөлкәтне индивидуальләштерү мөмкинлеге бирә торган белешмәләр булмаганда), анда түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

1) сайланган депутатлар саны;

2) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәгән депутатлар саны;

3) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын тиешенчә үтәмәгән депутатлар саны.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында депутатлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру бурычын үтәү (тиешенчә үтәмәү) хакындагы гомумиләштерелгән мәгълүматны урнаштыру Комиссиядән әлеге мәгълүмат кергән көннән алып җиде көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты тарафыннан башкарыла.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының дәүләт граждан хезмәткәрләре әлеге Татарстан Республикасы Законы нигезендә үз бурычларын үтәгәндә аларга билгеле булган белешмәләрне фаш иткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.»;

2) 13 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында депутат гарызнамә белән үз компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан төзелә яисә сайланып куела торган башка органнарның вазыйфаи затларына (Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларыннан тыш), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 03 апрель
№ 22-ТРЗ